**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«31» май 2025 ел № 59/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Комсомол авыл җирлеге Уставы нигезендә Комсомол авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Комсомол авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

авыл җирлеге милек хокукын туктатуны (читләштерүне) таләп итми торган күчемсез мөлкәт белән эш итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Комсомол авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (tukay.tatarsatan.ru) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Комсомол авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Комсомол авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Муниципаль берәмлек Башлыгы О.В. Сурова